

Яшь, эшлекле, гади. Эльмира Кутуева-Еряшева шушы кvркәм сыйфатлары белән хезмәт коллективында да, дуслары арасында да зур абруй яулаган. Мордовиядәге азык-толек иминлеге, агымдагы елда регионыбыздагы эпизоотия ситуация турында, ветеринария даруларын дорес куллануны тикшерv һәм дәvләт карантинынын фитосанитар нәтижәләре, бортекле ашлыкнын һәм орлыкларнын сыйфатын, аны эшкәртv саклыгын тикшерv, авыл хужалыгы карамагындагы дәvләти жирләрне кvзәтv эшләрен Мордовия Республикасы һәм Пенза олкәсе Россельхознадзор Идарәсе башкара. Бу олкәдә унышлы эшләп килгән яшь ветеринария белгечлеге алган хезмәткәрләр байтак. Шуларнын берсе – Ельник районы Усад авылында 1991нче елны колхоз председателе булып хезмәт иткән Кярим Кямил улы белән бухгалтер Роза Халим кызынын гаиләсендә туып, Ельник урта мәктәбе, аннары Н.П.Огарев исемендәге МГУнын аграр институты ветеринария бvлеген кызыл дипломга тәмамлаган Эльмира Кярим кызы Кутуева-Еряшева белән аралашырга туры килде.       Киләчәккә планнары белән кызыксындым.Әйтеп китәргә кирәк, ул беренче сыйныфтан ук киләчәктә кем булуын белгән. Эльмира бик тә хайваннар ярата һәм кечкенәдән ук vзләренен сыерларын, тавыкларын, этләрен ашатырга булышкан, кирәк вакытта дәвалау чараларында да катнашкан. Ветеринар профессиясе турында кызыксынган һәм кvп укыган. Алтын медаль белән мәктәпне тәмамлап, Мордовия университетында ветеринар-терапевт белгечлеге буенча тирән белем алган, жәмгыять эшендә актив катнашкан, яналыклар белән кызыксынган Эльмира Кярим кызы Россельхознадзор Идарәсенен дәvләт ветеринар бvлегендә хокvмәт инспекторы дәрәжәсендә хормәтле Чумарин Ринат Камиль улы житәкчелеге астында хезмәт итә.
- Бvген Мордовия Республикасы һәм Пенза олкәсе Россельхознадзор Идарәсе 5 юнәлеш буенча эшли. Мордовиядә - 90, Пензада - 70 белгеч, 20 - кече персонал, транспорт паркы хезмәткәрләре алга куелган бурычларын тормышка ашыра. 2015нче елнын 5нче апрелендә Мордовия Республикасы һәм Пенза олкәсе Россельхознадзор Идарәсенен барлыкка килvенә 10 ел тулды. Ә Россиядәге бу хезмәткә - 11. Илнен фитосанитар

куркынычсызлы гын тәэмин итvгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру ветеринария һәм фитосанитария кvзәтчелеге буенча федераль хезмәт һәм анын территориаль органнарына йокләнгән. Шуна без торле тикшервләр vткәрәбез. Безнен бvлек ашамлыкларнын сыйфатвын кибетләрдә, ашханәләрендә, кvбрәк балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә, продукцияне житештерv урыннарында ойрәнеп, анализлар алып башка олкәләргә дә тикшерергә жибәрәбез. Нәтижәләре безгә килгәч, Идарәбез постановление чыгара һәм предписанияләр яза. Аннары нәтижәсен тормышка ашыру буенча кабат контроль тикшерv vткәрәбез. Предписанияләребезне vтәмәгән очракта, андый очраклар бик сирәк була, эш нәтижәләрен судка да бирәбез, ди белгеч Эльмира Кярим кызы Еряшева.- Шулай, 2016 елнын 9 ае эчендә 188 тикшерv vткәрдек, аларнын: 24 план буенча, 86 плансыз һәм 78 рейдлысы. Контроль-надзор мероприятияләре буенча 56 предписание, 101 административ протокол тозелде. Куелган штрафлар суммасы - 412,6 мен сум.
Ул тикшерv нәтижәләреннән берничә мисал китерде. Дәvләт инспекторлары Ромодан районы МБОУ «Пушкинская основная общеобразовательная школа»да терлекчелек продукциясен саклау һәм эшкәртv буенча ветеринар-санитар таләпләрне бозу очрагын ачыклаганнар. Шулай, накладнойлар буенча ашханәнен әзерләv бvлегендә 7,31 кг бройлер кош ите ветеринар документсыз: ветеринар-санитар экспертизасыз һәм инфекцион авырусыз жирдәнме алынганлыгы билгесез булган кош итенә тап булганнар. Бу очрак укучылар саулыгына зыян китерергә һәм инфекция таратырга унай шартлар тудырган. Тикшерv нәтижәсе буенча мәктәп житәкчесенә (дело об административном правонарушении, предусмотренном частью 1 статьи 10.8 КоАП РФ) таләпләрне бозган очен предписание буенча 3000 сумга штраф билгеләнгән. Үткән тугыз ай эчендә контроль терлекчелек товарларнын 3,605 тонна продукциясен кире кайтарганнар һәм 86,3 килограммны сатудан алдырганнар; тәртип урнаштырганнар.
 - Бизнесны да тикшерv астында тотарга кирәк, ди Э.К.Еряшева. - Әле генә Ләмберә районы Атемарда африкалы дунгызы чумасы вирусын республикабызга кертмәv һәм таратуны кисәтv максаты белән дәvләт ветеринар надзор бvлеге хезмәткәрләре белән планнан тыш тикшерv vткәрдек, ди. Шәхси эшмәкәр Л.С. Люкшинанын Атемарда кибетләре бар. Анда вакыты чыккан хайваннар продукциясен саклау һәм сату очрагына тап булдык. Продукция остендә ясалу вакыты һәм каян чыкканлыгы булмаганга, холодильниклар һәм кибет почрак булганга  ИП Л.С. Люкшинага протокол тозеп 20 мен сум штрафка предписание билгеләнде, ди. Яхшы эшләр турында да әйтеп китәргә телим. Россельхознадзор сайтында vткән елдан алып «Чынлыклылар списогы - Список честных» дигән рубрикада чынлыклы (нефальсифицированный) сот ашамлыкларын житештерv предприятияләре турында мәгълумат туплыйбыз. Бvгенгә АО «Агрофирма «Октябрьская» (РМ, Лямбирский район, с.Большая Елховка)  житештерv предприятиясендә алдан тикшерv турында әйтмичә тозсыз акмай (массовая доля жира 72,5%)  тикшерелде. Нәтижәсе тvбәндәге: «Чынлыклылар списогы»на беренче буларак Мордовиядә АО «Агрофирма «Октябрьская» керде. Шундый тикшерv нәтижәләре безне шатландыра. Ил нигезе тырыш хезмәттә дип юкка гына әйтмиләр. Тырышып эшли ул; профессиональ югары бәя бирә житәкчеләре һәм хезмәттәшләре. Коллективы хормәт итә аны.
Эльмира Кярим кызы турында берничә сvз. Ул рус авылында туса да, ана телендә иркен аралаша. Ельник рус мәктәбендә укый. Шуна карамастан, татар мәдәнияты белән кызыксына. Әти-әнисе тосле милли бәйрәмнәребезне зурлый. Пәрәмәчне, кыймакны

тәмле пешерә. Менә шундый булдыклы ул. Бүген киләчәк буын вәкиленнән илебез тагы да зур унышлар көтә.

**Наилә Насырова**